Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре,Совет мәйданы, 27

тел. 3-15-25, 3-16-25

Республика Татарстан

Муниципальное образование город Арск
Арского муниципального района
Совет города Арск
422000, г. Арск, Площадь Советская , 27

тел. 3-15-25, 3-16-25

**Арча шәһәр Советы**

**КАРАР**

**30 май, 2024 ел** **№124**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Арча район Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Арча шәһәре башкарма комитетына:

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатыннан, бюджет законнары нигезендә Арча шәһәр Советының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты турында карарына үзгәрешләр кертү турында карары проектын эшләргә һәм карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

“Арча шәһәре” муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе

«Совет
города Арск»

И.Г.Нуриев